ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д16,
с.Емелькино, 423056

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕМЕЛЬКИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урамы,16 нче йорт
Емелькино авылы , 423056

Тел. (8-84344-4-76-22) ОГРН 1061665002101,
ОКПО 94318599, ИНН/КПП 1603004783/160301001
E-mail: *Emel.Aks@tatar.ru*, http://Aksubayevo.tatarstan.ru

# КАРАР

«05» апрель 2021ел. № 3

Емелькино авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Емелькино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (19.12.2019 ел, №17; 26.10.2020 ел, №9 редакциясендә) 26.12.2018 ел, № 14 карарына үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (3 нче кушымта):

- 1.5 пунктының беренче абзацы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (Өземтә) астында түбәндәгеләр аңлана: хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе, элекке яшәү урыныннан белешмә, көнкүреш характеристикасы»;

- 2.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3) гариза:

- кәгазь чыганакта документ рәвешендә. (1нче кушымта);

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә (интерактив формага тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла);

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булган очракта, һәм, әгәр федераль закон нигезендә мондый персональ мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын алуны раслаучы документларны өстәмә рәвештә тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар шул исәптән электрон документ формасында тапшырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);

- почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.».

1 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://Aksubayevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Емелькино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Н.И.Михайлова

1 нче кушымта

_______________________________________ына
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы иseme)

_______________________________________тан
(ФИА)

_______________________________________,
(паспорт мәгълүматлары)

Адрес буенча яшәүче:_______________________
(белешмә, яшәү урыны буенча теркәлү)

_______________________________________

Ышаныч буенча ___________________________
(Ф.И.А., ышаныч номеры)

_______________________________________

_______________________________________
(телефоны)

**Белешмә бирү (өземтә) турында**
**ГАРИЗА**

Белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм

_______________________________________
(белешмә төрен күрсәтергә)

Адрес
буенча:_______________________________________

Гаризага түбәндәге документларны теркım:

1. _______________________________________

2. _______________________________________

3. _______________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм _______________________________

_______________/______________/______________________
(дата) (имза) (Ф.И.А.)